# Гимадиева Мәрвиҗамал Сирай кызы



Гимадиева Мәрвиҗамал Сирай кызы 1930 елның 15 нче июнендә Балык Бистәсе районы Сатлыган авылында туган. Сугыш башланганда аңа бары 11 яшь кенә була. Инде кул арасына керә башлаган вакыты гына бик күп кайгы-хәсрәт күрергә туры килә аңа. Әтисен сугышка алып китәләр һәм ул анда батырларча һәлак була. Гаиләдә өч бала үсәләр.Укуга сусаган үсмер кызга белем алырга мөмкинлек булмый. Бары тик 2 ел гына укып кала. Олылар белән бергә колхоз эшенә йөргән:үгез җиккән, урак урган, көлтә керткән. Гомумән аның кулы аша нинди генә эш үтмәгән. Колхозның иң авыр эшләрен башкарырга туры килә аңа. Ватан азатлыгы хакына барлык авырлыкларга чыдаганнар, фронтны азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итү өчен, көнне төнгә ялгап эшләгәннәр. Җылы оекбаш, бияләйләр бәйләп, фронтка җибәргәннәр. Сыкранмый, сызланмый һәммәсен дә үз җилкәләрендә күтәрәләр алар.

Мәрвиҗамал апа бик тырыш гаиләдә үскән. Ашарга бәрәңгеләре булган. Шулай да ачлы-туклы яшәргә туры килә. Нәрсә туры килсә шуны ашаган алар: кычыткан, кузгалак, алабута кебек үсемлекләр белән җан асраганнар. Кияргә кием, ашарга икмәк булмаган. “ Шуңа да берәр ризыкның әрәм-шәрәм булып аунап йөргәнен күрсәм, күзләремә яшьләр тыгыла,-ди Мәрвиҗамал апа,-Их теге чакларда күпме хыялландык без бу ризыклар турында”. Әтиләре әзерләгән утынны ягып бетергәч, нәни чаналар белән ерак урманнан утын ташыганнар. 1945 нче елның 9 нчы мае! Өзелеп көткән Җиңү көне, ниһаять, килеп тә җиткән һәм исәннәр туган авылына әйләнеп кайткан. Тик Мәрвиҗамал апаны гына бу шатлык урап узган. Әтиле балаларны күреп йөрәге әрнегән. Шуңа да ул ”Ходаем беркемгә дә ятимлекне күрсәтмәсен,”-ди.

Сугыштан соңгы елларда да Мәрвиҗамал апа бик күп еллар хезмәт итүен сөйли. Хөкүмәтебезгә рәхмәтләрен укый, Мәрвиҗамал апа. Бүгенге көндә вакытында пенсиясен ала. Сугыш елларындагы хезмәтен хөкүмәтебез олылаган- медаль тапшырган. Мәктәп балаларының да онытмаганын, бәйрәмнәр белән котлауларын әйтә.

Әйе, тылдагы хезмәт ияләре шул ук фронттагы сугышчылар кебек үк көрәштеләр. Аларның хезмәт урыннары шулай ук сугышчан пост булды.